СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 301 от 28.06.2019

на № _______ от _______________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы нигезендә, Саба муниципаль районында гражданнарның җирле үзидарәне гамәлгә ашыру хокукын гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм Саба муниципаль районы җирле үзидарә вазыйфаи затлары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә халыкның фикерен ачыклау һәм аны исәпкә алу очен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне расларга (теркәлә).

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм (http://saby.tatarstan.ru) адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы                                    Р.Н. Минниханов

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
28.06.2019 ел, 301 нче карары белән

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнарны сораштыру (алга таба – сораштыру) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы халкының турыдан-туры ихтыяр белдерүенең бер формасы булып тора.

Сораштыру аша гражданнарның җирле үзидарәне гамәлгә ашыру хокукы тәэмин ителә.

1.2. Сораштыру Саба муниципаль районында яшәүчеләрнең яисә аның бер өлешенең җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча фикерләрен ачыклау һәм җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары карарларын кабул иткәндә аны исәпкә алу алымыннан гыйбарәт.

1.3. Сораштыру нәтиҗәләре тәкъдим итү характерында була.

## 2. Сораштыруны үткәрү принциплары

2.1. Гражданнарны сораштыруда Саба муниципаль районында яшәүче сайлау хокукына ия булган халык катнаша ала.

2.2. Саба муниципаль районында яшәүче халык сораштыруда тигез нигезләрдә катнаша. Сораштыруда катнашкан һәр кеше бер тавышка ия һәм сораштыруда турыдан-туры катнаша.

2.3. Сораштыруда катнашу очен гражданнарның җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, чыгышына, молкәтенә һәм вазыйфаи хәленә, дингә монәсәбәтенә, инануларына, иҗтимагый берләшмәләргә каравына бәйле нинди дә булса турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган чикләүләр рохсәт ителми.

2.4. Гражданнарны сораштыруда катнашу ирекле һәм ихтыяри булып тора. Сораштыру барышында беркем дә үз фикерләрен һәм инануларын белдерергә яки алардан баш тартырга мәҗбүр ителә алмый.

2.5. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары халыкка сораштыруда катнашу хокукын гамәлгә ашыруда ярдәм итәргә бурычлы.

## 3. Сораштыруга кертелә торган мәсьәләләр

3.1. Сораштыруга кертелергә момкин булган мәсьәләләр:

– Саба муниципаль районында яшәүче халык мәнфәгатьләренә турыдан-туры кагылышлы һәм Саба муниципаль районы Уставы тарафыннан җирле әһәмияткә ия мәсьәләләргә кертелгән;

– региональ һәм регионара әһәмияттәге объектлар очен муниципаль берәмлек җирләренең максатчан билгеләнешен үзгәртү турында.

3.2. Сораштыруга чыгарыла торган мәсьәләләр Россия Федерациясе

законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына, Саба муниципаль районы Уставына каршы килергә тиеш түгел.

Сораштыруга чыгарыла торган мәсьәләләр аларга күп яклы анлатма бирү мөмкинлеген калдырмаслык итеп формалаштырылырга тиеш.

## 4. Сораштыру төрләре

4.1. Сораштыру яшерен, исемләп яки ачык тавыш бирү юлы белән үткәрелә.

4.2. Яшерен тавыш бирү сораштыру үткәрү пунктларында бер кон дәвамында сораштыру кәгазьләре буенча үткәрелә.

4.3. Исемләп тавыш бирү сораштыру кәгазьләре яки сораштыру исемлекләре буенча сораштыру үткәрү пунктларында да, сораштыруда катнашучыларнын яшәү урыны буенча сораштыру үткәрү комиссиясе әгъзалары тарафыннан бер яки берничә кон дәвамында үткәрелә.

4.4. Сораштыру шулай ук гражданнар җыелышларында ачык тавыш бирү рәвешендә үткәрелә ала.

## 5. Сораштыруны билгеләү тәртибе

5.1. Саба муниципаль районы территориясендә гражданнарны сораштыру үткәрелә:

1) район Советы яки район Башлыгы инициативасы белән – җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы белән - республика һәм регионара әһәмияттәге объектлар очен район җиренец максатчан билгеләнешен үзгәртү турында карарлар кабул иткәндә гражданнар фикерен исәпкә алу очен.

5.2. Саба муниципаль районы Советы карамагындагы сораштыру үткәрү инициативасы әлеге орган тарафыннан сораштыру билгеләү турында тиешле карар кабул ителүдә чагыла.

Саба муниципаль районы Башлыгы карамагындагы сораштыру үткәрү инициативасы район Советына сораштыру үткәрү турындагы үтенечнамә юллауда чагыла.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы карамагындагы сораштыру үткәрү инициативасы әлеге орган тарафыннан Саба муниципаль районы Советына сораштыру үткәрү турындагы үтенечнамә юллауда чагыла.

5.3. Сораштыру үткәрү турындагы үтенечнамәдә күрсәтеләләр:

– сораштыру үткәрү мотивлары;
– сораштыруга чыгаруга тәкъдим ителә торган мәсьәләнец (мәсьәләләрнец) формулировкасы;
– сораштыру территориясе;
– сораштыру үткәрүнец ниятләнгән датасы һәм аныц төре.

5.4. Гражданнарны сораштыруны билгеләү турындагы карар Саба муниципаль районы Советы тарафыннан кабул ителә.

5.5. Сораштыруны билгеләү турындагы карар сораштыру үткәрү турындагы үтенечнамәне алганнан соц 30 коннән дә соцга калмыйча һәм аны үткәрүгә кадәр 30 көннән дә соцга калмыйча кабул ителергә тиеш. Сораштыру билгеләү турында карарны кабул итү алдыннан Саба муниципаль районы Советы тарафыннан сораштыруга чыгарылган мәсьәләнец (мәсьәләләрнец) формулировкасы сораштыру инициаторы белән килепгерелә.

5.6. Әгәр мәсьәләнең (мәсьәләләрнең) формулировкасы гамәлдәге законнарга, әлеге Нигезләмәгә каршы килсә, Саба муниципаль районы Советы инициаторга сораштыру үткәрүне кире кага.

5.7. Саба муниципаль районы Советының гражданнарны сораштыру үткәрүне билгеләү турындагы карарында билгеләнә:

1) сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары;

2) сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган мәсьәләнең (мәсьәләләрнең) формулировкасы;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазе формасы;

5) сораштыруда катнашучыларның минималь саны.

5.8. Сораштыру билгеләү турындагы карар аны үткәрүгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча мәҗбүри басылып чыгарга тиеш.

## 6. Сораштыру үткәрү буенча комиссия

6.1. Гражданнарны сораштыруны әзерләү һәм үткәрүне сораштыру үткәрү комиссиясе (алга таба - Комиссия) башкара.

6.2. Комиссия, инициаторлар тәкъдимнәре нигезендә, сораштыру үткәрү территориясеннән чыгып, Саба муниципаль районы Советы тарафыннан 3-15 кеше дән билгеләнә.

6.3. Комиссия составына Саба муниципаль районы Советы, Башкарма комитеты вәкилләре, шулай ук сораштыру үткәрелә торган территориянең җәмәгатьчелек вәкилләре кертелә.

6.4. Комиссия аны оештыру турында карар кабул ителгәннән соң өченче көннән дә соңга калмыйча чакырыла. Беренче утырышта Комиссия ачык тавыш бирү юлы белән комиссия рәисен, комиссия рәисе урынбасарын һәм комиссия секретарен сайлый, сораштыру участокларын раслый, шулай ук сораштыру, сораштыру үткәрү пунктларында үткәрелгән очракта, мондый пунктларның санын һәм урынын раслый.

Комиссия утырышларын аның рәисе зарурлыктан чыгып чакыра. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы санала.

Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Комиссия гражданнарны сораштыруны үткәрү өчен кирәкле санда эш төркемнәре булдырырга хокуклы.

Сораштыру участоклары, комиссиянең урнашу урыны һәм гражданнарны сораштыру үткәрү пунктларының урнашу урыннары сораштыру уздырыласы көнгә кадәр 10 көннән дә ким булмаган вакыт эчендә бастырып чыгарылырга (игълан ителергә) тиеш.

6.5. Сораштыру үткәрү буенча комиссия:

– гражданнарны сораштыруны уздырган вакытта әлеге Нигезләмәнең үтәлешен оештыра;

– сораштыру үткәрү пунктларын җиһазлый;

– сораштыру кәгазьләрен яки сораштыру исемлекләрен әзерләүне тәэмин итә;

– сораштыру вакытында имзалар җыюны оештыра;

– Саба муниципаль районында яшәүче халыкның сораштыруда катнашуын тәэмин итә ;

– әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән тәртиптә сораштыру вакытында

халыкның тавыш бирүен оештыра;

– Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, иҗтимагый берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итә;

– гражданнарны сораштыру нәтиҗәләрен билгели;

– гражданнарны сораштыруны үткәрү белән бәйле гаризалар һәм шикаятьләрне карый;

– гамәлдәге законнар һәм әлеге Нигезләмә нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

6.6. Комиссия вәкаләтләре Саба муниципаль районы Советы тарафыннан үткәрелгән сораштыру нәтиҗәләре рәсми басылып чykканнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) туктатыла.

6.7. Комиссия эшчәнлеген матди-техник, оештыру ягыннан тәэмин итү Саба муниципаль районы Советы аппараты тарафыннан башкарыла.

## 7. Сораштыру участоклары. Сораштыруда катнашучылар исемлеге

7.1. Сораштыру участогы - сораштыру үткәрү комиссиясе тарафыннан билгеләнгән гражданнарны сораштыру үткәрелә торган Саба муниципаль районы территориясе.

Сораштыру территориясе бердәм сораштыру участогы тәшкил итә ала.

Сораштыру участокларында сораштыру үткәрү вакытында тавыш бирү өчен махсус җиһазландырылган бүлмәләр булырга тиеш. Участокларда сораштыру вакытында тавыш бирүне комиссия әгъзаларының берсе җитәкләгән участокларга җибәрелгән комиссия әгъзалары тәэмин итә.

7.2. Сораштыруда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган муниципаль берәмлектә яшәүчеләр кертелә. Исемлектә сораштыруда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшь тулганнарга өстәмә - көне һәм ае) һәм яшәү урыны күрсәтелә. Кешене конкрет сораштыру үткәрү участогына сораштыруда катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез булып аның яшәү урыны бу участок территориясендә булу факты тора. Кеше сораштыруда катнашучылар исемлегенә сораштыру үткәрү буенча бары бер участокта гына кертелә.

Сораштыруда катнашучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә һәм комиссия рәисе һәм исемлек төзегән секретарь тарафыннан имзалана.

Әлеге Нигезләмә нигезендә сораштыруда катнашу хокукына ия кешеләр исемлегенә өстәмә кертү теләсә кайсы вакытта, шул исәптән сораштыру уздырылган көнне дә рөхсәт ителә.

Тавышларны санау башланганнан соң сораштыруда катнашу хокукына ия кешеләр исемлегенә үзгәрешләр кертү тыела.

Сораштыруда катнашучылар исемлеге сораштыру үткәрүгә 3 көннән дә соңга калмыйча төзелә.

## 8. Сораштыру кәгазе

8.1. Сораштыру кәгазендә сораштыруга чыгарылган сорауның (сорауларның) төгәл текст күчермәсе һәм “Риза” яки “Каршы” сүзләре белән тавыш бирүченең ихтыярын белдерү вариантлары күрсәтелә, алар астында буш квадратлар урнаштырыла.

Сораштыруга берничә сорау чыгарганда, алар бер сораштыру кәгазенә кертелә, эзлекле рәвештә нумерлана һәм бер-берсеннән горизонталь линияләр белән аерыла.

Нинди дә булса статьяның яисә сораштыруга чыгарылган норматив хокукый актның нинди дә булса пункты проектының альтернатив редакцияләре шулай ук эзлекле рәвештә нумерлана.

Исемләп тавыш бирү өчен кулланыла торган сораштыру кәгазендә тавыш бирүче турында мәгълүматлар кертү өчен буш урын булырга тиеш.

Сораштыру кәгазендә аны тутыру тәртибе турында аңлатма бирелә. Сораштыру кәгазенең өске уңъяк почмагында комиссия рәисе һәм секретареның имзалары куела.

## 9. Сораштыру исемлеге

9.1. Сораштыру исемлеге исемләп тавыш биргәндә кулланыла һәм графаларына сораштыруда катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны турында мәгълүматлар кертелә торган таблицадан гыйбарәт. Әлеге графалардан уң якта сораштыруга чыгарылган мәсьәләнең (мәсьәләләрнең) төгәл тексты күчермәсе астында “Риза” яки “Каршы” сүзләре белән тавыш бирүченең җавап бирү вариантлары күрсәтелә һәм тавыш бирүдә катнашучыларның имзасы өчен урын калдырыла.

Сораштыруга берничә сорау чыгарылганда, алар сораштыру исемлегендә эзлекле урнаштырыла.

9.2. Сораштыру исемлеге һәр битгә комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

## 10. Сораштыруны үткәрү тәртибе

10.1. Сораштыру гражданнарны сораштыру үткәрү турындагы карарда Саба муниципаль районы Советы тарафыннан билгеләнгән көнне (яки көннәрдә) үткәрелә.

10.2. Гражданнарны сораштыру сораштыру үткәрү пунктларында җирле вакыт буенча иртәнге сәгать сигездән кичке егерме сәгатькә кадәр үткәрелә.

## 11. Сораштыру үткәргәндә яшерен тавыш бирү тәртибе

11.1. Яшерен тавыш бирү яшерен тавыш бирү өчен махсус җиһазландырылган урыннары булган һәм тавыш бирү вакытына печатьләп алынган тартмалар куелган сораштыру үткәрү пунктларында үткәрелә.

11.2. Сораштыру кәгазе тавыш бирүчегә сораштыруда катнашучылар исемлеге буенча комиссия әгъзалары тарафыннан бирелә. Сораштыру кәгазен алган вакытта тавыш бирүче паспорт яки шәхесне һәм яшәү урынын раслаучы башка документ күрсәтә һәм сораштыруда катнашучылар исемлегендә үз фамилиясе каршына имза куя. Сораштыруда катнашучылар исемлегендә паспорт мәгълүматларын тутыру таләп ителми.

11.3. Әгәр тавыш бирүченең сораштыру кәгазен алганлыкка үзе имза кую мөмкинлеге булмаса, ул, комиссия әгъзаларыннан тыш, башка зат ярдәменнән файдаланырга хокуклы.

Сораштыруда катнашучыга ярдәм күрсәткән зат “Сораштыру кәгазен алу турында сораштыруда катнашучының имзасы” графасында үзенең фамилиясен күрсәтеп имза куя.

11.4. Сораштыру кәгазе тавыш бирүче тарафыннан башка затларның булуы рөхсәт ителмәгән, махсус җиһазландырылган урында (кабиналарда яки бүлмәләрдә) тутырыла һәм тавыш бирү тартмасына төшерелә.

Тавыш биргәндә сораштыруда катнашучы үзенең ихтыяр белдерүенә туры китереп “Риза” яки “Каршы” сүзе астындагы квадратга теләсә кайсы билгене куя.

Комиссия әгъзалары сораштыруның яшереилегеи тәэмин итәләр.

Әгәр тавыш бирүче сораштыру кәгазен тутырганда хата ясадым дип саный икән, ул сораштыру кәгазен биргән комиссия әгъзасына, аңа бозылганы урынына яңа сораштыру кәгазе бирү үтенече белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Комиссия әгъзасы тавыш бирүчегә яңа сораштыру кәгазе бирә, шул ук вакытта сораштыруда катнашучылар исемлегендә әлеге катнашучы фамилиясенә янына тиешле билге ясый. Бозылган сораштыру кәгазе гамәлдән чыгарыла, ул хакта комиссия әгъзалары тарафыннан тиешле акт тозелә.

Тутырылган сораштыру кәгазьләре тавыш бирүче тарафыннан комиссия әгъзаларының күз уңында булырлык итеп урнаштырылган тартмага тошерелә.

Тартмалар саны комиссия тарафыннан билгеләнә. Тавыш бирү очен күчмә тартмалар кулланып тавыш бирүне үткәрү турындагы мәсьәләне комиссия мөстәкыйль хәл итә.

11.5. Әгәр комиссия әгъзасы сораштыру яшеренлеген боза яки сораштыруда катнашучыларның үз ихтыярын белдерүенә йогынты ясарга омтыла икән, ул кичекмәстән аның эшендә катнашудан читләштерелә. Читләштерү турындагы карар, әлеге участокта комиссия эшен җитәкләүче комиссия әгъзасы тарафыннан әлеге участокта сораштыру үткәрә торган комиссия әгъзаларының имзаларын куйдырып тиешле беркетмә тозеп, кабул ителә.

## 12. Сораштыру вакытында исемләп тавыш бирүне үткәрү тәртибе

12.1. Исемләп тавыш бирү сораштыру үткәрү пунктларында да, гражданнарның яшәү урыны буенча да үткәрелергә мөмкин.

12.2. Исемләп тавыш бирү сораштыру кәгазьләре буенча да, сораштыру исемлекләре буенча да үткәрелә ала.

12.3. Сораштыру исемлекләре буенча исемләп тавыш биргәндә тавыш бирүче, паспорт яки шәхесне һәм яшәү урынын раслаучы башка документын күрсәтеп, сораштыру исемлегендә фамилиясе каршындагы үзенең ихтыяр белдерүенә туры килгән графада теләсә нинди билгене куя һәм имзалый.

12.4. Сораштыру кәгазьләре буенча исемләп тавыш биргәндә тавыш бирүче фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, адресын сораштыру кәгазенә үзе яза, үз ихтыяр белдерүенә туры китереп, “Риза” яки “Каршы” сүзләре астына, квадратта теләсә нинди билгене куя һәм шунда ук имзалый.

Сораштыруда катнашучы үтенече буенча сораштыруда катнашучы турындагы белешмәләрне сораштыру кәгазенә комиссия әгъзасы да кертә ала, әмма тиешле квадратка билгене тавыш бирүче үзе куя һәм имзалый.

12.5. Сораштыру үткәрү дәвамында һәр кон ахырында тутырылган сораштыру кәгазьләре, сораштыру уздырган затлар тарафыннан, комиссиягә китерелә.

12.6. Сораштыру кәгазе буенча тавыш бирү мәгълүматлары комиссия әгъзалары тарафыннан сораштыру исемлегенә күчерелә, ул сораштыру нәтиҗәләрен билгеләү өчен төп документ булып тора.

## 13. Сораштыру үткәргәндә ачык тавыш бирү тәртибе

13.1. Сораштыруда катнашучы кешеләр саны 1000 кешедән артмаса, сораштыруга чыгарылган мәсьәлә (мәсьәләләр) буенча тавыш бирүне үткәрү очен, комиссия сораштыруда катнашучылар җыелышын үткәрергә хокуклы. Җыелышта катнашучыларны теркәү сораштыруда катнашучылар исемлеге буенча үткәрелә. Җыелышны оч кешедән дә ким булмаган комиссия вәкилләре ачалар һәм алып

баралар. Җыелышта кызыксынучы якларның сораштыру өчен чыгарылган мәсьәлә (мәсьәләләр) буенча чыгышлары, аларның гражданнарның сорауларына җавап бирүе рөхсәт ителә, әмма фикер алышулар үткәрелми.

13.2. Җыелышта тавыш бирү һәр мәсьәлә буенча ачык: “Риза” өчен аерым һәм “Каршы” өчен аерым - үткәрелә. Тавыш бирүдә исемлеккә кертелгән һәм җыелышта теркәлгән сораштыруда катнашучылар гына катнаша ала. Тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә, ул җыелышта катнашучы барлык комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

13.3. Сораштыруда катнашучылар исемлегенә кертелгән халыкның 25 процентан артыгы катнашканда җыелыш тулы хокуклы санала.

## 14. Сораштыру нәтиҗәләрен билгеләү

14.1. Сораштыру үткәргәннән соң, комиссия сораштыру участоклары буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен исәпли һәм үзенең сораштыру нәтиҗәләре турындагы карарын түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелгән беркетмә белән рәсмиләштерә:

– беркетмә төзү датасы;
– сораштыру үткәрү вакыты: башлану һәм тәмамлану даталары;
– сораштыру үткәрү участогы адресы;
– сораштыру территориясе (сораштыру район территориясенең бер өлешендә үткәрелгән булса, авыл җирлекләре, торак пунктларның, урамнарның, йортларның номерларының исемнәре мәҗбүри күрсәтелә);
– сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителгән мәсьәләнең (мәсьәләләрнең) формулировкасы;
– сораштыруда катнашу өчен исемлеккә кертелгән гражданнарның гомуми саны;
– сораштыруда катнашкан гражданнар саны;
– сораштыруны узган яисә узмаган дип тану;
– сораштыруны дөрес яки дөрес түгел дип тану;
– сораштыру исемлегендә гамәлгә яраксыз дип танылган язмалар саны яки гамәлгә яраксыз дип танылган сораштыру кәгазьләре саны;
– сораштыруга чыгарылган мәсьәләгә җавап биргәндә “Риза” дип бирелгән тавышлар саны;
– сораштыруга чыгарылган мәсьәләгә җавап биргәндә “Каршы” дип бирелгән тавышлар саны;
– сораштыру нәтиҗәләре (әгәр сораштыруда катнашкан тавыш бирүчеләрнең яртысыннан артыгы “Риза” дип җавап бирсә, мәсьәлә хупланган дип санала).

14.2. Әгәр сораштыру берничә мәсьәлә буенча үткәрелгән булса, һәр мәсьәлә буенча тавышлар аерым санала һәм беркетмә аерым төзелә.

Сораштыру кәгазендәге язмалар дөрес түгел дип таныла, әгәр:

– сораштыруда катнашучыларның фикерен ачык итеп билгеләү мөмкин булмаса;
– язмада тавыш бирүче турында мәгълүматлар яки аның имзасы булмаса;
– кабатланган язмалар булса.

Сораштыру кәгазьләре дөрес түгел дип таныла, әгәр:

– билгеләнгән үрнәктә булмаса,
– комиссия әгъзаларының тамгалары булмаса,
– алар буенча сораштыруда катнашучыларның фикерен ачык итеп

билгеләү мөмкин булмаса.

14.3. Әгәр сораштыруда катнашкан халык саны Саба муниципаль районы Советының сораштыру үткәрүне билгеләү турындагы карары белән билгеләнгән сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлек халкының минималь санынннан әзрәк булса, Комиссия сораштыру узмаган дип таный.

14.4. Комиссия сораштыру нәтиҗәләрен дорес түгел дип саный:

– сораштыру уздырган вакытта җибәрелгән хокук бозулар гражданнарның ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен ачык итеп билгеләргә мөмкинлек бирмәсә;

– әгәр сораштыру исемлегендә гамәлдә дип танылган язмалар саны, сораштыруда катнашкан гражданнар санының 80% тан кимен тәшкил итсә;

– әгәр гамәлдә дип танылган сораштыру битләре саны сораштыруда катнашкан гражданнар санының 80% тан кимен тәшкил итсә.

14.5. Сораштыру нәтиҗәләре турында беркетмә 2 нөсхәдә төзелә һәм комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәгә кул куйган вакытта комиссиянең кайбер әгъзалары булмаган очракта, беркетмәдә, аларның юклыгы сәбәпләрен күрсәтеп, бу хакта тамга ясала.

Беркетмә белән тулысынча яки аның аерым нигезләмәләре белән килешмәгән комиссия әгъзасы язма рәвештә аерым фикер белдерергә хокуклы. Аның аерым фикере беркетмәгә теркәлә һәм бу хакта беркетмәдә тиешле язма бирелә.

Беркетмә, әгәр ул Саба муниципаль районы Советы карары белән сораштыру үткәрү буенча комиссия әгъзалары санының күпчелеге тарафыннан имзаланса, гамәлдә дип санала.

Беркетмәне имзалау көне комиссия әгъзалары тарафыннан сораштыру нәтиҗәләрен билгеләү көне булып тора.

14.6. Беркетмәнең беренче нөсхәсе - сораштыру кәгазьләре яки сораштыру исемлекләре белән бергә Саба муниципаль районы Советына, икенче нөсхәсе сораштыру үткәрү инициаторына җибәрелә.

Беркетмәнең беренче нөсхәсенә комиссиягә кергән язма шикаятьләр, гаризалар һәм алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлә. Шикаятьләрнең, гаризаларның һәм алар буенча кабул ителгән карарларның расланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә теркәлә.

Беренче нөсхәнең күчермәләре массакүләм мәгълүмат чараларына, җирле иҗтимагый берләшмәләргә һәм территориаль иҗтимагый үзидарә органнарына бирелергә мөмкин.

14.7. Саба муниципаль районы Советы һәм комиссия сораштыру үткәрү буенча документларның сакланышын һәм тутырылган сораштыру кәгазьләре һәм сораштыру исемлекләренең кагылгысызлыгын тәэмин итә.

## 15. Сораштыру нәтиҗәләре

15.1. Сораштыру нәтиҗәләре аны үткәргәннән соң бер ай вакыт эчендә бастып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

15.2. Сораштыру барышында ачыкланган халык фикере тәкъдим итү характерына ия. Сораштыру нәтиҗәләре мәҗбүри карап тикшерелергә һәм Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә исәпкә алынырга тиеш.

15.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан сораштыру нәтиҗәләренә каршы килә торган карарлар кабул

ителгән очракта, күрсәтелгән органнар тиешле карар кабул ителгәннән соң 10 кон эчендә тиешле мәгълүматны бастырып чыгару (халыкка игълан итү) юлы белән мондый карар кабул итүнен сәбәпләрен халыкка җиткерергә тиеш.

## 16. Сораштыру материаллары саклау

16.1. Сораштыру материаллары Саба муниципаль районы Советында Саба муниципаль районы Советы депутатларыныц вәкаләтләре срогы ахырына кадәр саклана, аннары муниципаль архивка саклауга җибәрелә.

16.2. Күрсәтелгән материалларны саклау срогы Саба муниципаль районы Советы тарафыннан билгеләнә, әмма 1 елдан да ким булырга тиеш түгел.

## 17. Сораштыру үткәрүне финанслауны тәэмин итү

17.1. Гражданнарны сораштыруны әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чараларны финанслау башкарыла:

– җирле бюджет акчалары хисабына - җирле үзидарә органнары инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә;

– Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына - Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә.

## 18. Гражданнарның сораштыруда катнашу хокукларын бозган өчен җаваплылык

18.1. Россия Федерациясе гражданының сораштыруда катнашу хокукын ирекле гамәлгә ашыруга янсо комиссиянен яки комиссия әгъзаларыныц эшенә коч куллану, сатып алу, янаулар, ялган документлар ясау юлы белән яки башка ысул белән комачаулаучы затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылык тоталар.